СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2023 г. Заинск № 152

**Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 декабрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын тикшерү буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясына таянып, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре расланган көннән алып 5 көн эчендә территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының җир мәсьәләләре, экология һәм ТКХ буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Р.В. Агләмов).

**Совет рәисе** **Р.Г.Кәримов**